УДК 821.512.145

*Д.Ф. Заһидуллина*

# ФАТИХ ӘМИРХАН: ТАТАР ХАЛКЫ ӨЧЕН ЯНЫП ЯШӘҮ

Статья посвящена жизни и творчеству татарского прозаика и драматурга, публициста и журналиста Фатиха Амирхана. Рассматриваются малоизвестные факты из жизни, журналистской деятельности, сделана попытка обобщающей оценки творческой эволюции писателя. Установлено, что Ф. Амирхан стал одним из первых авторов татарской романтической прозы, мастером психологизма. Впервые в татарской драматургии он представил к вниманию татарского читателя психологические драмы. Ф. Амирхан обращается к художественному потенциалу разных литературных направлений: реализма, романтизма, модернизма. Он является сторонником идеи прогресса татарского народа, в критике и публицистике выступал за развитие национального образования, науки, культуры.

**Ключевые слова:** татарская литература, Фатих Амирхан, возрождение нач. XX века, психологизм, романтизм.

The article is devoted to the life and work of the Tatar novelist and playwright, publicist and journalist Fatih Amirkhan. Little-known facts from life and journalistic activity are considered and an attempt is made to generalize the assessment of the writer's creative evolution. It is established that F. Amirkhan became one of the first authors of Tatar romantic prose, a master of psychology. For the first time in Tatar drama he presented psychological dramas to the attention of the Tatar reader. F. Amirkhan addresses the artistic potential of various literary trends: realism, romanticism, modernism. He is a supporter of the idea of the progress of the Tatar people, in criticism and journalism he advocated the development of national education, science and culture.

**Keywords:** Tatar literature, Fatih Amirkhan, renaissance of the beginning. Twentieth century, psychologism, romanticism.

*(Дәвамы. Башы журналның 1 нче санында)*

## «Хәят»

Ф. Әмирхан прозасының гына түгел, татар әдәбиятының таҗы – «Хәят» повестен әдип 1909 елда яза башлап, 1911 елның 18 июлендә тәмам итә. Повесть шул ук елны 88 битле җыентык рәвешендә дөнья күрә һәм тиз арада укучыларның яраткан китабына әверелә. Татар дөньясында язучының әсәрнең икенче кисәген язуы хакында сүз тарала, укучылар тизрәк аның тәмамлануын көтәләр. Әмма бу мәсьәлә ачык кала.

Инде совет чорында язучы һәм әдәбият галиме М. Мәһдиев журналист Сәхи Рәхмәтинең А. Шамовка юллаган хатыннан кызыклы мәгълүматлар китерә: «...Ләкин "Хәят"ның икенче бүлеге чыкмый калды. Сәбәбе шул: 1911 елда "Хәят"ның беренче бүлеге басылып

чыгып бераз вакыт магазиннарда сатылгач та, бу китапта тасвир ителгән Хәят Г.ның хатыны Ү. ханым икәнлеге бөтен Оренбург халкына, бигрәк тә әдәбият белән шөгыльләнүчеләргә мәгълүм була. Күп тә вакыт үтми, Г. “Хәят”ның магазиннарда булган бөтен нөсхәләрен сатып алып яндырта һәм “Хәят”ның икенче кисәгенең кулъязмасын бөтен хокуклары белән ун мең сумга сатып алды, дигән хәбәр тарала» [7: 67]. Өзектән күренгәнчә, киләчәктә әсәр дәвамының табылуы зур шик астына куела.

2001 елда Галимҗан Шәрәфнең улы Арыслан ТР Милли музеена тапшырган материаллар арасында повестьның 6 дәфтәргә теркәлгән икенче өлеше табыла һәм 2016 елда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнеп, бастырып чыгарыла [14].

Повестьта сурәтләнгән тормыш яшьлек, аның да мәхәббәт көтү дәверенә кагыла. 16 яше дә тулмаган Хәятның күңелендә Михаилга, Галигә карата кызыксыну уяну, акылның бу кызыксынуны ярату хисенә үстерми туктатып калуы, чибәр һәм самими кызның, үзе ярәшелгән егеткә мәхәббәт бирүен сорап, Аллага ялваруы... Төп сюжет сызыгын Хәят күңелендә барган үзгәрешләр тәшкил итү авторның романтизм сукмагында каләм сынавын дәлилли.

Повестьның беренче өлеше унҗиде бүлеккә аерылган, һәрберсенең исеме бар. Күпчелек бүлекләрдә катнашучыларның репликалары исемгә чыгарылган (1 нче бүлек: «Ах, Хәят, нинди матур син...»; 6 нчы бүлек «Хәят, мин сезне сөям!»; 9 бүлек «Алар безгә, без аларга буласы түгел»; 10 бүлек «Без нәрсәгә әни сүзенә карыйбыз?»; 12 нче бүлек «Без белешмәсәк тә, белешүче табылган»; 16 нчы бүлек «Барыбер кайчан да булса бер бармый хәл юк»). Бу репликалар вакыйгаларга катнашучыларның билгеле бер караш ноктасын күрсәтеп тора. Бүлек исемнәрендә үк тормышның каршылыклы кабул ителүе ассызыклана.

Повестьның моңа кадәр билгеле өлешендә төп сюжет сызыгы Хәят күңелендәге мәхәббәт көтүдән кияүгә чыгарга карар кылуга кадәрге аралыкны колачлый. Бу сюжетны «мәхәббәт көтү тарихы» дип атарга мөмкин. Аны хәрәкәткә китерүче конфликт Хәяттагы хис һәм акыл көрәше, гаилә (иске татар көнитеше, татар җәмгыятендәге кануннар, тирәлек) белән Хәят күзаллаган идеал тормыш арасында булып чыга. Хис һәм акыл үзгәреше бәхеткә, ireккә, үзең теләгәнчә яшәргә омтылышның – моның мөмкин түгеллеген аңлау, ризалашу, буйсыну белән алмашынуы арасында тирбәлә. Вакыйгалар үстерелеше Салих Фатихов фотосын күргәннән соңгы икеләнүләрдә иң югары ноктага – кульминациягә җитә. Чишелеш – Хәятның үзе күрмәгән-белмәгән, әмма ата-аналары бирергә теләгән егеткә кияүгә чыгарга карар итүе. Ләкин әсәр соңында кызның Аллага ялваруы («Илаһи, мәхәббәт бир!») каршылыкның чишелүе дә, ата-ана кушуы белән мәхәббәткә ирешү дә мөмкин түгеллекне раслый.

Тышкы каршылыклар исә Хәят һәм аның тирәлеге, иң элек, гаиләгә бәйле туа. Хәятның әти-әнисе аны традицион дини карашларга

туры китереп тәрбияли: бу, беренче чиратта, намаз һәм дини китаплар укытуда, мөселман ир-егетләре белән танышырга рөхсәт итмәүдә (хәтта очраклы очрашулар вакытында чит кешеләрдән йөзне каплау) күренә. Бер үк вакытта Хәят балачактан Лиза Мясникова белән дус, аның гаиләсе, абыйсы Михаил белән таныш. Мясниковлар гаиләсе тормышы Хәятлар көнитешеннән нык аерыла: Лиза һәм Михаил дөньяви белем алалар, өйләрендә еш кына яшьләр өчен бию кичәләре оештырыла.

Мясниковлар белән аралашу Хәят өчен эзсез үтми: ул русча иркен сөйләшә һәм укырга өйрәнә, әлегә кадәр дини-дидактик эчтәлекле «Дөррәтен-нәсыйхин»нар белән чикләнгән кыз яңа китаплар дөньясына килеп керә, ул үзен рус студентлары белән аралашканда да бик иркен тота. Бер үк вакытта Хәятның иҗтимагый хәле Әминә һәм аның апасы Рокыяның хәле белән аваздаш. Димәк, рус яшьләре белән иркен аралашсалар да, татар хатын-кызлары хокуксыз, сайлау ирегеннән мәхрүм булып чыга. Аларның киң тормышка омтылуы исә, язучы карашынча, күп яктан заманның тиз үзгәреше белән бәйле. Мәсәлән, Әминә студент Степанов белән мөнәсәбәтләре хакындагы сорауга болай җавап бирә: «Юк, белеш түгел; белешләнергә теләмим дә: андый егетләрне читтән торып сөяргә генә ярый... Сөй, сөймә, барыбер, туганым, алар безгә, без аларга буласы түгел бит инде» [14: 45]. Хәят та, Михаил турында уйлый башлауга, алар арасында мәхәббәт булу мөмкин түгеллекне, бу хиснең киләчәге юклыкны исенә төшерә: «Менә башка шушы соңгы уйлар килгәндә, Хәят кинәт Михаил белән үз арасында үтеп булмый торган чокыр барлыгын сизде. Ничектер, моны әүвәл бер пәрдә белән каплап торганнар да, кинәт ул пәрдәне тартып алып, аның артында капланып торган салкын һәм куркыныч нәрсәне күрсәтеп калдырганнар шикелле итеп, күңеленә килгән китеклекне ул хәзер генә аңлап җитте: “Михаил мөселман түгел бит, ул кяфер бит”» [14: 36].

16 нчы бүлектә Хәят белән Әминәнең сөйләшүе кызларның заманча уйлап та («...ул сине сөяме, син аны сөя аласыңмы икәнен белмәгән кешегә гомерлеккә хатын булу куркыныч»), ата-аналары теләгән кешегә кияүгә чыгуларын («Барыбер, кайчан да булса бер бармый хәл юк») [14: 72] аңлатып килә. Язучы моны әсәр буенча гаҗәеп оста файдаланылган күпсанлы, төрле характердагы детальләрдә ассызыклап бара. Менә бер мисал: «Бүлмәнең сул стенасына эленгән кыйммәтле урман рәсеменә каршы, уң стенага бик яхшы рам эченә тыгылган, хатты куфи белән язылган “Аятелкөрси” куелган иде дә, “урман”, хатты куфига карап, көлеп тора, хатты куфи, “урманга” карап, кашларын җыерып, ачуланып тора шикелле иде» [14: 44]. Лексик антиномия биредә XX йөз башы татар тормышына кагылышлы бәягә әйләнә: рәсем һәм дини аять янәшә урын яуларга, икесе гармониядә яшәргә омтылган вакытны белдерә.

Төп сюжет үзе өч ярдәмче сюжет сызыгына, ягъни шул ук акылхис каршылыгына нигезләнгән мөстәкыйль өч тарихка таркала.

«Михаилның Хәятка мәхәббәт аңлату тарихы», «Хәятның Гали Арсланов белән танышырга теләү тарихы», «Хәятның Салих Фатиховка кияүгә чыгарга карар кылу тарихы» алар. Ярдәмче сюжет сызыклары охшаш төзелгән: егетләр белән бәйле күңелдә кызыксыну уяну, өметләр һәм икеләнүләр агышы пәйда булу, карар кабул ителү кебек үсә һәм тәгәлләнә.

Яңа табылган дәвам өлеше өч бүлекне колачлый: 18 нче бүлек «Йөрәк ашкынмый, ыргытылмый, артык сизелүлек бернәрсә тоймый...», 19 нчы бүлек «Ят, билгесез һәм куркыныч кеше», 20 нче бүлек «Сөям бугай...». Әлеге өч бүлекне «Хәятның Салих Фатиховка кияүгә чыгу тарихы» дип атап булыр иде. Һәр бүлек бер зур вакыйганы үзәккә куя: 18 нче бүлек – туй, 19 нчы бүлек – Идел буйлап пароходта сәяхәт, 20 нче бүлек – Салих өендә тормыш. Бу бүлекләрдә дә хәрәкәтне Хәятның каршылыклы мөнәсәбәте, хис һәм акыл көрәше барлыкка китерә. Акылның яратмаган Салихны аңларга тырышуга, аклауга, яратам дип уйлауга этәрүе, хиснең исә һәр мизгелдә кыз идеалы белән тәңгәл килмәгән детальләргә игътибар итә баруы күзгә ташлана. Мәсәлән, 18 нче бүлектә Хәятның беренче тәэсирләрен сурәтләгәндә үк әдип шушы эчке каршылыкны калкуландыра: «Шактый вакытлар узгач кына Хәятның күз алдын каплап тора торган томан акрын гына тарала башлады һәм бары шул вакытта гына ул Салихның матур һәм сөйкемле егет икәнен шактый ачык итеп күрде. Ләкин бу матурлык, бу сөйкемлелек Хәятта үткен бер тойгы тудыра алмады: күзләр рәхәтләнәләр, әмма йөрәк ашкынмый, ыргытылмый. Артык сизелерлек бернәрсә тоймый иде, ки тойгы ничектер бер читендәрәк яшеренеп, нәрсәгәдер юл куеп тора шикелле иде. Хәят кыска гына бер вакытта Салихның үзенә “ир”, үзенең аңар “хатын” икәнлеген дә уйлап алды. Ләкин бу уй да аның йөрәгендә әллә нинди үткен сизелерлек бер тойгы кузгата алмый, әллә ничек ялкау вә салкын уйлана иде: Салихның “ир-кияү” булучылыгы, Хәятның аңар “хатын” булучылыгы бертөрле заказ кушылып эшләтелгән, гадәт шулай булганлыктан эшләнгән нәрсә шикелле иде, ки болар һәр икесенә үткен йөрәкне катырак вә ешрак типтерерлек булып сизелми иде. Азан ишеткәч, дога укый башлау – ашап бетергәч, бит сыпырып кую кебек, теләү-теләмәүгә карамыйча, үзүзеннән эшләнеп ташлана торган эшләр шикелле, Хәятның Салихка “хатын” вә Салихның аңар “ир” булуы да, теләү вә кирәксенүдән бигрәк, “тиешлек” өчен эшләнгән эш төсле иде, ки күңел вә тойгы әллә ничек катышмыйча читтә вә керешсез калган иде» [14: 81].

Тышкы каршылыклар да шул ук: хәзер инде Хәятның эти-әнисе, туганнары урынын – кайнанасы, аның күзаллаулары, мөнәсәбәте били. Беренче каршылык кияү белән күрешкәндә аның кулын үбәргәме, юкмы дигән сорау тирәсендә туа һәм Хәятның әнисе Газизә абыстай белән дусты Әминәнең фикерләре төрлелеге моның өлкән буын белән замана яшьләренең карашлар аерымлыгы булуын ассызыклый: «Хәят үзе дә Әминәчә уйласа да, эшкә килгәч, анасы сүзен

тотумы яки туганы сүзен тотумы яхшырак, килешләрәк буласын ачык билгеләп йиткерә алмый апдырады. Әллә нинди бер һавалылык аңар туганымы сүзен тотарга куша иде. Моңар кадәр аны чолгаган рус егетләре үзләре аның, Хәятның, кулын үбә иделәр; бүген генә инде ул иң әүвәл күргән бер егетнең кулын әүвәл күрешүдә үк һичбер сәбәпсез үзе үпсә, кызлыкның, матурлыкның хөрмәтен җуйган була шикелле; Хәят моны үз-үзенә ачык әйтеп күрсәтә алмаса да, йөрәгенең әллә кайсы бер чите белән шулай итеп аңлый иде. Ләкин икенче яктан әллә нинди белемсез бер курку аңар анасы сүзен тотарга куша, аны көчли, ирексезли дә аптырашда калдыра иде. Бераз аптыраш... яңадан бераз аптыраш... аннан соң курку җиңде дә, Хәят күңеленең теләмәвенә вә риза булмавына карамыйча, анасы сүзен тотарга, ягъни Салихның кулын үбеп күрешергә уйлап беркетеп куйды. Бу карар Хәятның кызлык көннәренең соңгы карары булды» [14: 79].

Үз заманы татар тормышында да руслар белән аралашып яшәү ягыннан аерылып торган Хәятлар гаиләсе белән чагыштырып, әдип Салихның «артык европалы» түгеллеген күп кенә детальләрдә күрсәтә. Мәсәлән, Хәят егетнең кайбер рус сүзләрен дөрес әйтмәвен искәрә. Әмма артык яңалык яклы булмаган Салих белән аның әнисе Гаделбану абыстай арасында да күп кенә мәсьәләләрдә каршылык туа. Моны язучы Салихның уйларында варенье савыты кую, яки рус повар алуга бәйле анасы белән ике арада туган каршылыкларны искә төшереп, аннары Салихның русларны өенә кунакка чакыру күренешен хәтерләтеп сөйли.

Хәят белән Гаделбану абыстай арасындагы мөнәсәбәтләрне дә язучы шушы якка игътибар итеп сурәтли: аларның икесенең дә күңел халәте яңача уйлау белән искечә фикерләү каршылыгы төсендә ачылып китә.

Повестьның матурлыгы, эмоциональ тәэсирлелеге, шиксез, төп образ бирелеше белән турыдан-туры бәйле. Хикәяләүче үз героинясы Хәятны сокланып, кызның уй-фикерләрендә, хис-кичерешләрендә калкып чыккан каршылыкларга битараф калмыйча тасвирлый.

Әсәрнең күпчелек өлеше Хәятны характер буларак ачуга хезмәт итә. Язучы аның портретын әсәр буенча «сибеп» бара: «Матур бу кызның озын керфекле кара күзләре алсу-ак йөзенә, могҗизалы якутлар шикелле, нур чәчеп торганлыктан, гүзәл башы, хәтта бөтен буе нурда йөзә шикелле күренә иде»; «Ул озын, куе вә үз-үзләреннән күперенеп тора торган, кара ефәк көлтәсе шикелле чәчләрен тараганда…» һ. б. Тышкы кыяфәтне һәм холык-фигыльне сурәтләү максатында, башка геройларның бәяләре кулланыла. Алар кызның матурлыгын да, эчке самимилеген һәм сафлыгын да ассызыклыйлар.

Ләкин иң әһәмиятлесе – хикәяләүче аңлатмалары, аның, психологизм алымнары кулланып, Хәят күңелендә туган хис-кичерешләрне, аңында бер-берсен алыштырып килгән фикерләрне укучыга «сөйләве». Кызның эчке дөньясы, нигездә, шулар аша тергезелә. Бу вакытта язучы аң агышы алымы ярдәмендә Хәятның күңел халәтен

күзәтә. Болар арасында хис һәм акыл көрәшен тергезгән урыннар аеруча мөһим һәм алар хәрәкәт хасил итә.

Бу үзенчәлек повестьның яңа табылган дәвамында да күзгә ташлана. Әмма биредә инде мәхәббәт көтү белән бәйле хис һәм акыл көрәше түгел, үз хәле белән килешергә омтылудан туган каршылыклы халәт ачыклана. Әйтик, Салихның соңаруын сурәтләгән соңгы вакыйгада язучы героинясының кичерешләрен болай аңлата: «Шулай булды инде, бер көнге шикелле төнлә генә кайтыр инде! – дип, Хәят башына килгән фикерен теле белән әйтеп, үз-үзенә аңлатты. Аның эче поша иде. Бу эч пошу Салихны сагынгандан түгел, Салихны әллә нинди хатыннар янында йөри торгандыр дип уйлап көнләшкәннән түгел, Салих белән менә хәзер эшләнергә тиешле бер эш булып да, шул эшнең вакытыннан кичеккәненнән түгел, хәтта Салихны кәефләнеп кайтып, үзен кәефсезләндерер дип уйлаудан да түгел, бәлки коры, билгесез рәвештә эч пошу иде. Хәятта Салихка каршы үткен бер тойгы юк, шунлыктан ул аны сагынып көтми, Салихны Хәят бозык бер фахиш дип дә уйламый, шуңар күрә, ул аннан көнләшми; Салихның кәефләнеп кайтуы аңар бер көн кәефсез булса да, әүвәлге мәртәбәдәге пароходтагы шикелле үк үткен тоелмаган вә шуңар күрә ул хәзер аның тугрысында да куркынып уйланмый, бәлки үзенә мәгълүм булмаган пошыну белән пошына иде» [14: 103–104].

Бу аңлатуга Хәятның гына түгел, яратмаган, белмәгән-күрмәгән кешесенә кияүгә чыккан татар кызларының хәленә ачыну, сызлану килеп катнаша. Әгәр повестьның төп текстында Хәятның индивидуальлеге үзәктә торса, дәвам өлешендә типиклаштыру, Хәят язмышын татар кызлары язмышы кебек гомумиләштереп бәяләү калкытып куела.

Әсәр исеменә чыгарылган һәм төп героиня исеме булган, татар яшьләре хәяты дигән җыелма образда уйнатылган символның дәвам өлешендә татар хатын-кызы язмышы мәгънәсе алга чыга. Аңа каршы куелган йорт образы Салих йорты мисалында яңа яклары белән күренә башлый. Традицион татар көнитешен матур һәм бай итеп бәяләү белән бергә, язучы аның яңалыкны кабул итмәвен дәвам өлешендә дә ассызыклый.

Беренче өлештә парлы символлар – роза чәчәге һәм сандугач әсәрне лирик-эмоциональ дулкынга көйли. Чәчәк – Хәятка бәя бирә: хикәяләүче кызны матур чәчәккә охшата, Михаил исә аны кояшта сулган чәчәк белән чагыштыра. Шулай итеп, чәчәк – яшьлек, матурлык, мәхәббәт символы, ул яшьлекнең матурлыгын да, тереклекне-матурлыкны саклап кала алмау ачысын да ассызыклый. Хәятның кияүгә чыкканнан соңгы тормышы әлеге сулган чәчәк белән тиңләшә. Моның өчен язучы янәшәлек алымына мөрәҗәгать итә. Туйлары августта булган яшьләрнең пароходта йөзүләре җилле салкынча вакытка, Хәятның кияү өендә яши башлавы исә караңгы кыш көннәренә туры килә. Кыз тормышындагы үзгәрешләр шулай бәяләнә.

Хәятны гомумән татар кызы буларак уку вариантын әкәм-төкәм һәм карлыгач символлары да калкуландыра. Беренче карашка, алар

аллегория булып тоела һәм Гали Арсланов уенда калкып чыга: «Бу егет… татар кызлары хакында кайсыбер рус китапларында күргән нәрсәләрен генә белә вә шуңар күрә аларны – кабыгына яшеренеп ята торган әкәм-төкәмнәр шикелле итеп кенә күз алдына китерә ала иде» [14: 53]. Бераздан язучы образны Хәят белән Әминәгә күчерә: «Галинең зиһенендәге төркем-төркем әкәм-төкәмнәр янына тагы ике әкәм-төкәм кушылды. Шулкадәр аерма бар: Галинең әүвәлдән белә торган әкәм-төкәмнәре былчыраклар, әмма бу соңыннан килеп кушылганнары өс якларыннан чиста вә нәфисләр иде» [14: 55]. Укучы күзаллавында исә әкәм-төкәм образы Хәятның үз гаиләсе, милләте, традицияләре кысасыннан чыга алмавы белән янәшә куела, кызның карарларына бәя булып аңлашыла. Вакыйгадан вакыйгага Хәят татар тормышындагы традицияләрне үзгәртә алмаячагын аңлый бара. Рәхимә абыстай Гали Арслановны кызлар белән таныштырудан баш тарткач, хикәяләүче мондый күзәтү ясый: «Күңел үзенең ирексезлеген һәм әллә нинди бик тупас бау белән буыла икәнен сизенеп пошынды. Хәятның эч пошу эчендә нәрсәдер аның үзенә белеш түгел бер нәрсә күңелнең пошынуы белән сугышырга тотынды» [14: 57]. 12 нче бүлек ахырында, Хәят Гали Арсланов һәм Ольга биюен күзәткәндә, ул тагын калкып чыга. 13 нче бүлектә («Яшерен елаш») ирексезлекне аңлау Рокыя мисалында күрсәтелә. Шулай әдип иреккә омтылган героинясын ата-анасы фикере белән килешеп, кияүгә чыгарга ризалашуга китереп җиткерә. Бигрәк тә әсәрнең дәвамы өлешендә Хәятның психологик яктан үз күңелен көйләргә, үз хәле белән ризалашырга омтылышы күңелендә карлыгач йөрткән кызның әкәм-төкәм кабыгында калу мәҗбүриятен, шушы хәлнең драматизмын бөтен тулылыгында ача.

Героиня өчен әһәмиятле һәр вакыйга аның күңелендә каршылыклы уйлар һәм хисләр көрәшен уята, бу исә эч пошуга китерә. Эч пошу – Хәятның үзе дөрес түгел дип тапкан ситуациядән чыгу юлын таба алмавы ул. 18–20 нче бүлекләрдә исә бу халәт даими калкып чыгып тора, бу аларның тулаем диярлек эчке монолог кебек язылулары белән дә аңлатыла. Язучы Хәятның кияүгә чыкканнан соңгы халәтен мәхәббәткә өмет итеп тә, аңа ирешү мөмкин түгеллекне аңлау белән бәйли.

Әсәрнең дәвамында читтән торып ясалган психологик анализ да урын таба: «Гаделбану абыстай сүзләрендә вә мөгамәләсендә Хәятка үзенең аны әллә ничек, бигүк сөеп бетермәгәнлеген белдертмәскә тырышса да, Хәят йөрәгенең әллә кайсы бер чите белән бу эшне сизенә, ләкин аңа бик зур әһәмият бирмәскә тырыша, үз-үзен әһәмият бирмәскә ирексезли иде» [14: 100].

Шулай итеп, повестьның психологик стильдә язылуын, авторның әсәрнең дәвамын эшләгәндә дә сайланган язу рәвешенә тугры калуын билгеләргә кирәк. Героиняның күңелендә барган үсеш-үзгәрешне күзәтеп барып, язучы татар кызының матурлыгын аны чолгап алган тормышның кырыслыгына каршы куя. Үз хыялында гына булса да

Хәят тормышны үзгәртергә, гармониягә китерергә омтыла, бу вакытта аның өчен иң мөһим башлангыч булып мәхәббәт тора. Әмма кызның күңел хәрәкәте мәхәббәткә, бәхеткә, ирекка, үзең теләгәнчә яшәргә ашкынудан – моның мөмкин түгеллеген аңлау, ризалашу, буйсынуга таба юнәлә. Хәятның эш-гамәлләре дә татар кызының иҗтимагый шартлардан котыла, күнегелгән гадәтләрдән читкә чыга алмавы турында сөйли. Хәят тарихы гомумән татар хатын-кызлары язмышына әверелә, ХХ йөз башы татар җәмгыятендә яшьләрнең яңача яшәргә, хөрлеккә омтылуын, ләкин иске тәртипләрнең бу омтылышларны чикләвен аңлата. Әмма бу тарих матурлык теле белән иҗат ителгән, шуңа да ул романтик кимәлдә кала, күрсәтелгән омтылышларның гүзәллеген ассызыклый, татар кызының тышкы матурлыгына, акылына, уй-фикерләр табигыйлегенә сокланырга мәҗбүр итә, шулар аша аның хөр, ирекле, азат булачагына ышаныч саклана.

Җамал Вәлиди: «ул татар әдәбиятын заман теләгенә мауфыйк бер калыпка, Көнбатыш әдәбияты калыбына салды, аңа җитди бер форма биреп, телне, өслүбне нечкәләп эшкәртүче булды. Ф. Әмирхан – кирәк фикер ягыннан булсын, нәфис әдәбиятыбызны гареблэштерүдә[1] иң алдан чыгучы һәм киң юлдан ачучыдыр» [6: 433], диюе белән хаклы иде. Бу сүзләрнең дөреслеге «Хәят» повесте мисалында да раслана.

## Совет чынбарлыгы һәм Ф. Әмирхан

ХХ йөз башы татар әдәбияты тарихында Ф. Әмирхан иҗаты әдәбиятны идея-эстетик яктан үзгәртүләрне башлап җибәрүе, милли мәдәниятне күптөрле тәҗрибәләр аша үстерүе һәм бу вакытта шәркый традицияләрне урынлы куллануы белән үзенчәлекле. 20 нче еллар әдәбияты өчен бу иҗат – 1917 елга кадәр формалашкан юнәлешне саклаучы, татар әдәбиятының фикри һәм форма ягыннан казанышларын югалтмыйча, алдагы буыннарга тапшырырга ярдәм иткән нигез баганаларыннан. Язучы шәхесе исә – гражданлык фидакярлеге үрнәге буларак аерым хөрмәткә лаек.

1917 елгы февраль инкыйлабын Ф. Әмирхан тормышның үзгәрәчәгенә өмет белән каршы ала. «Кояш» газетасының март һәм апрель саннарында «Инкыйлаб вә без» дигән зур мәкалә, «Аң» журналының 3–4 саннарында «Богаулар өзелделәр» дигән язма бастыра. Ул инкыйлабны милләтне үстерер өчен туган олы мөмкинлек, язмышның «киләчәгегез бу көннән соң үз кулыгызда» дип белдерүе кебек кабул итә. Ф. Әмирхан халык буларак бөтенлегебезне, традицияләр, гореф-гадәтләрне саклап калыр өчен, татарның «дини, милли, мәдәни автономия» төзү зарурияten куәтли, милләтне социаль катлауларга бүлмичә, сыйнфый тартышлардан, фетнәчел чыгышлардан ерак торырга чакыра. Биредә әдипнең ихластан илһамлануы, дулкынлануы күренеп тора.

[1] *Гареблэштерү* – Көнбатышка, Европага якынайту.

Әмма тиз арада Ф. Әмирхан мәкаләләрендә большевиклар сәясәтен дөрес юлга борып җибәрү, аерым мәсьәләләрдә эш башындагыларны татар халкы кебек азсанлы милләтләрнең яшәү үзенчәлеген исәпкә алмыйча эш йөртүдә тәнкыйтьләү чаткылары барлыкка килә. «Кызыл армия» газетасының 1919 елдагы 14 декабрь санында ул «Ләфызпәрәстлек[1] кенәме, лакейлыкмы?» дигән мәкалә бастыра һәм татарларда өстенлекле сыйныф буларак пролетариат сыйныфын игълан итүнең хакыйкатькә туры килмәгәнен расларга омтыла. Аның шушы юнәлештә иҗат ителгән мәкаләләрендә, бер яктан, инкыйлабның көткән азатлыкны бирә алмавына борчылу, икенче яктан, килеп туган вазгыятьтә үз халкына киләчәккә юл күрсәтү теләге үрелеп бара.

1918 елны Фатихның әнисе Рабига абыстай бакыйлыкка күчә. Иң якын кешесен югалтуны бик авыр кичергән Фатих аңа багышлап «Тәгъзия[2]» дигән нәсер иҗат итә. Ул 1922 елны «Әдәби ярдәм мәҗмугасы»[3]нда басылып чыга һәм татар әдәбиятында инкыйлабка кадәрге традицияләрнең саклануына бер дәлил булып яңгырый.

Ул әле генә бердәнбер кызларын җирләп кайткан ир белән хатынның сөйләшүе кебек язылган. Әмма бу сөйләшү – асылда, кайгыдан сыгылган, әмма хатынын юатырга омтылган картның монологы рәвешен ала. Аның фразалары, интонациясе аша хатынның җавапларын да тергезергә мөмкин.

Хатынына мөрәҗәгать итеп, ир кеше үлемнең – котылгысызлыгын, табигать законы булуын, бер җан иясенең дә аннан котылып кала алмавын искәртә. Карт сүзләрендә сер пәрдәсенә төрелгән үлем – яшәүнең бердәнбер мәгънәсе кебек калкулана. Шул ук вакытта Ф. Әмирхан иман мәсьәләсенә кагыла, өметсезлекне кичерә алу юлларын барлый (биредә үлгәннән соң яшәүнең мөһимлеге дә, һәр кешенең үз тирәсендәгеләргә яхшы мөгамәләсенең тормышны үзгәртә алуы да, җан тынычлыгы булганда гына хакыйкатькә ирешү мөмкин икәнлек тә һ. б. искәртелә). Күпмедер күләмдә әсәр 1920 елларда яңа хакимиятнең иманнан баш тартуын гаепләү булып та яңгырый («Ул газапларны, ул өмидсезлекне без матдәнең аргы ягына идракъләре[4] ирешми торган, күзләре күргәннән башканы гакыллары гына түгел, йөрәкләре дә сизми торган кызганыч бәндәләргә, динсезләргә калдырыйк. Сабырлары җитә икән, алар йөкләсеннәр шул газапларны, алар көйсеннәр шул өмидсезлек белән! Ә без, без, бу тереклектән башка тагын бер тереклек барлыкка ышанучылар, ул икенче тереклекнең безнең тереклегебезгә караганда чынрак, әһәмиятлерәк, галирәк икәнен аңлыйк, аңлыйк та ул тереклеккә күчкәннәр өчен өмидсезлеккә төшмик...» [11: 368]).

---

[1] *Ләфызпәрәстлек* – хәрефкә ябышып яту.

[2] *Тәгъзия* – күңел юату, сабыр итәргә өндәү; дини әдәби жанр атамасы.

[3] Бу елларда таратудан килгән акчасы ачларга ярдәм итүгә тотыла торган җыентыкларны шулай атыйлар.

[4] *Идракъ* – акыл.

Әсәр үзе хакыйкать, рухи ныклык хакындагы суфичыл дога кебек кабул ителә (моңа Урта гасырлар суфи әдәбияты жанрыннан алынган һәм бер үк вакытта әрвахларны искә алу йоласын белдерә торган әсәр исеме дә ишарә ясый). Бик нык уйланган композиция һәм сүзләрнең оста сайлануы, аң агышы укучының игътибарын үзенә җәлеп итә һәм күтәрә алмаслык олы кайгының һәр мизгелен күңелдән уздырырга мәҗбүр итә. Нәтиҗәдә, әлеге «эмоциональ күпер» укучы күңелендә дә хасил була.

1920 еллар башында Ф. Әмирхан инкыйлабка кадәрге әдәби традицияләрне дәвам иткән хикәяләр дә яза. «Беренче ашкыну» (1918) шундыйлардан. Аңа да «басылмаган озын хикәядән бер кисәк» дип аңлатма бирелгән. Хикәянең төп герое – авыл мулласының малае, шәһәр кызы Саррәгә гашыйк булган. Авылдан алып килгән карабодайны сатып бетерүгә, малай-егет, сөйгәнен күреп булмасмы дип, аларга йөгерә. Хәйлә табып, кызга мөрәҗәгать итү, аннары инде шәһәрдән авылга кайтып китү аралыгы беренче мәхәббәтнең матурлыгын, кеше күңелендә бихисап күп каршылыклы тойгылар уятуын күрсәтергә ярдәм итә. Дөрес, әсәр ахырында малай «бу көнге сагынуымда минем ул моңлы ләззәт һәм тыныч уйга бату юк, бәлки ниндидер бер ачылык, тынычсызлану, борчылу башлыча хөкем сөрәләр иде» [11: 365], ди. Бу мәхәббәтнең киләчәге булмау, чарасызлык кебек экзистенциаль мотив килеп керә. «Башымда караңгы һәм өмидтән ерак фикерләр йөренә башладылар». Ләкин социаль сәбәпләр белән уралып кергән бу халәт әсәрнең иң ахырында билгеләп кенә куела. Ә инде мәхәббәт уяткан хисләр палитрасы, уй һәм кичерешләрнең туктаусыз берсен берсе алыштырып килүе нәкъ менә беренче мәхәббәтнең тылсымлы тәэсирен сурәтләү үзәккә куелганлыкны исбатлый.

1921 елда Ф. Әмирхан әтисен югалта. Бертуган энесе Ибраһим бу вакытта Кырымда хокук саклау органнарында эшли. Якыннарыннан аерылу, 1921 елгы ачлык Фатихның болай да какшаган сәламәтлегенә зур зыян сала. Әдипнең тормышы авыр булганлыкны ул 1921 елның 7 октябрендә яза башлаган көндәлек дәфтәрләре күрсәтеп тора. Укучы бу дәфтәрләрдә 1920 елларның коточкыч атмосферасын да, инкыйлабның кешеләр аңына, күңеленә ясаган тискәре йогынтысын да, ачлыкны, мәдәни мохитне, шушы хәлләр уртасында калган талантлы татар зыялысы кичергәннәрне дә күз алдына китерә алыр. Татар мәдәниятендә Ф. Әмирхан кадәр инкыйлаби вакыйгаларга төгәл-тәнкыйди тарихи-экзистенциаль бәя биргән башка каләм әһеле булмый.

Октябрь инкыйлабының асылына төшенгән әдип 1917 елда ук «Март каһарманы» дигән хикәя язып, анда революциянең ни икәнен аңламаса да, үзе өчен файдасына төшенеп, митингтан митингка йөреп, социалист булып киткән, куштан һәм яраклаша белүче кеше тибын иҗат итә. Әлеге героен киләчәккә алып китеп, аның язмышын болай күзаллый: «1920 елда Русиядә кушма җөмһүрият урнашып

җиткән, татар штаты рәис җөмһүриятлегенә дә бер социалист сайланган, ләкин ул социалист безнең Гыйсмәтулла түгел иде. Гыйсмәтулла үз волостьларының комитетында кәтиб мөгавене[1] хезмәтен үтәп, аена йөз сум вазифа ала, социалистларны, хосусән, «бөтен инсаниятнең канын эчүче рәис җөмһүриятне» бик сүгә, халыкны анархист-индивидуалист булырга өнди һәм революция вакытында җыеп калган ун мең сум капиталының елга биш йөз сум гына процент бирүендә хәзерге «кан эчүче хөкүмәт»не гаепле күрә иде» [11: 330].

Яңа системаның асылын, идеологик нигезсезлеген аңлап, совет хакимиятенә шарж итеп язылган «Шәфигулла агай» (1924) повесте большевиклар идеологиясенең кешеләрне уйсыз-гамьсез, гасырлар буе яшәп килгән традицияләрдән аерылган кол дәрәҗәсенә төшерүен раслый. Язучы Шәфигулланың аяныч язмышы аша советчыл тәртипләрнең татар халкына рухи-әхлакый характердагы зур югалтулар китерүенә ишарә ясый. Язучы әлеге фикерне карнавал көлү – халык көлүе формасында, ирония, сарказм алымнарына таянып калкуландыра. Интеллектуаль һәм мәдәни яктан чикләнгән Шәфигулланың, тормыш алып килгән, көн саен радиодан яңгырый торган идеологик чакырулар, яңача яшәү рәвешен мактаулар тәэсирендә, «советча» яши башлавы: 20 ел бергә яшәгән хатыны Сәрвине аерып, кабат советча гаилә коруы, яңа туган улына большевикларча итеп Володя исемен куштыруы, аны, кызыл байракка төреп, кешеләргә күрсәтүе, сабый демонстрациядә салкын тидереп үлгәч, табут ясатып күмүе, көн саен балаларын «Интернационал» җырлатуы, Мәскәүгә «партийный хаҗ кылырга» китеп баруы һ. б. укучы тарафыннан акылдан язу буларак кабул ителә. Яңа идеологиянең тышкы билгеләре халык аңында киләчәк матур тормыш хакында миф тудыруга юнәлтелгән булса, Ф. Әмирханның бу идеологик йогынтыны «акылдан яздыру» буларак бәяләве әлеге рәсми мифны җимерүгә хезмәт итә. Язучы заман алып килгән үзгәрешләрне иҗтимагый яктан да, милли аспектта да бәяләп уза. Әйтик, повестьны тәмамлап, «Красный тел» газетасында басылган хәбәрдән китерелгән өзек милли сөйләмнең юкка чыгуы хакында сөйли: «Рабочий-крәстиянга тагын бер пример. Почти 60 яшенә достигать иткән татарин-рабочий Шәфигулла әле недавно гына партиягә расписаться иткән булса да, религиозный дурманнарны к черту җибәреп, полный сознательность проявить итте. Новорожденный ребенкасына Владимир куштырды...». Шул рәвешле, руслашу сәясәтенең көнитеш рәвешен һәм гореф-гадәтләрне генә түгел, гомумән миллилекне юк итүе билгеләнә.

Шул ук вакытта Ф. Әмирхан яңа чынбарлыкта үз урынын табарга омтыла. 1923–1924 елларда укыту эшенә кереп, Татар театр техникумында татар әдәбияты дәресләре алып бара, хәтта дәреслекләр дә язуда да катнаша. «Кызыл армия», «Эш», «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан» газеталарына мәкаләләр яза, аларда халыкны агарту, рухи

[1] *Кәтиб мөгавене* – секретарь.

үстерү юллары хакында уйлана. Әйтик, «Мәдәниләшү юлында зур адым» («Татарстан», 1922, 1 октябрь) мәкаләсендә татар теленең терминологиясен камилләштерү, философия, логика, психология, хокук кебек юнәлешләрдә төшенчәләр булдыру, терминологик сүзлекләр төзү турында сүз алып бара. «Бу рухта беренче…» («Безнең юл», 1925, № 3) язмасында Гыйльми үзәкнең Каюм Насыйриның тууына 100 ел тулу уңаеннан юбилей кичәсе уздыруын тәбрикләп, әдип татар халкын, аның төрле сыйныф вәкилләрен берләштерү, шулай итеп, халыкны үстерү мәсьәләсен көн тәртибенә куя.

Кызганычка каршы, бу елларда Ф. Әмирханга каршы чыгулар күбәя, аны буржуаз язучы буларак гаепләүләр яңгырый. Шулай да, Г. Ибраһимов тырышлыгы белән, 1925 елда Татарстан АССР хөкүмәте Ф. Әмирханга 40 сум күләмендә персональ пенсия билгели. Шул ук елны Әмирханда туберкулёз авыруы табыла. Хәле авырайгач, татар зыялылары аңа ярдәм оештыралар: табиблар булышлыгы, студентларның кизү торуы, зыялыларның килеп йөрүе, газеталарда көн саен аның хәле турында хәбәр ителү – халыкның Ф. Әмирханга мәхәббәтенең ачык чагылышы була.

Каты авырудан соң, 1926 елның 9 мартында әдип бакыйлыкка күчә. Бу вакытта аңа бары 40 яшь була.

Күмү мәрасиме комиссиясе саубуллашу чараларын тантаналы итеп оештыра (замандашлары аның Тукайны соңгы юлга озату дәрәҗәсендә булуын, театр мәйданына 2 меңләп кеше җыелганлыкны язып калдыралар). 12 март көнне башта театр мәйданында дөньяви митинг үткәрелә, аннары Юнысовлар мәйданында җеназа намазы укыла. Җәсәде Татар бистәсе зиратында дәфен кылына.

Бакый Урманче, әдипнең татар мәдәниятендәге урынын билгеләп, болай дип яза: «Безнең буын яшьләре, Көнчыгышның гасырлар буенча кристаллашкан, калыплашкан традицияләреннән ваемсыз читләшмичә, Европа-Көнбатыш мәдәниятенә йөзне юнәлдергән прогрессив зыялының идеаль моделе итеп Фатих Әмирханны таный иде. Әдип – үз заманындагы җәмгыять корылышы мәсьәләләрен, бөек француз революциясе аша килгән гаделлек, азатлык, тигезлек идеалларын Көнбатышның революцион фикерле алдынгы ирләре кебек аңлаган шәхесләрнең берсе, һәм бу хосусият аның әсәрләрендә генә түгел, бәлки көндәлек шәхси тормышында да табигый чагылыш тапты. Ф. Әмирхан каләме иҗат иткән әсәрләр алдынгы татар яшьләренең самими өметләренә куәт биреп, алар фикеренә шифалы һәм бәрәкәтле йогынты ясап килде» [15: 50].

Чыннан да, гыйлем һәм фән кешеләре биргән мәшһүр нәселнең затлы улы Фатих Әмирхан үзенең тирән акылы, күпкырлы эшчәнлеге, бай иҗаты белән татар халкы тарихына «аяклары бәйле Прометей» булып язылa (Х. Туфан, «Могикан», 1969). Кешеләргә ут бүләк иткән грек пәһлеваны кебек, Ф. Әмирхан милләттәшләренә йөрәк, акыл, рух утын бирә, аларны да янып яшәргә, башкаларга һәм милләткә файдалы булырга өнди.

## Әдәбият

1. *Ахмадуллин А.Г.* Татарская драматургия: Истоки и формирование социалистического реализма. М.: Наука, 1983. 263 с.

2. Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек. 2 томда. 1 т. / төз.: Р.Н. Даутов, Р.Ф. Рахмани. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 751 б.

3. «Әлислах» газетасының библиографик күрсәткече / төз. Р.Ф. Мәрданов. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1991. 78 б.

4. *Әмирхан Р.* Әмирханнар (тәфсилле шәҗәрә). Казан: Мәгариф, 2005. 125 б.

5. *Ганиева Р.* Татар әдәбияты һәм Фатих Әмирхан // Мәгърифәт. 1996. 13 февр.

6. *Җамал Вәлиди.* Әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз.: Д. Абдуллина, Ж. Миңнуллин. Казан: Җыен, 2010. 624 б.

7. *Мәһдиев М.* Ф. Әмирхан. Тормышы һәм иҗат юлы турында кыскача очерк. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 86 б.

8. *Нигматуллин Э.Г.* Татарская литература нач. XX века (до 1917 года) в её отношении к западноевропейской литературе и философско-эстетической мысли: дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1972. 232 с.

9. *Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1966. 427 б.

10. *Рәми И.Г., Даутов Р.Н.* Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек). Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 399 б.

11. *Фатих Әмирхан.* Әсәрләр: дүрт томда. 1 т.: хикәяләр (1907–1922). Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 480 б.

12. *Фатих Әмирхан.* Әсәрләр: дүрт томда. 3 т.: публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 512 б.

13. *Фатих Әмирхан.* Әсәрләр: дүрт томда. 4 т.: әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 390 б.

14. *Фатих Әмирхан.* Хәят. Казан: ТӘһСИ, 2016. 308 б.

15. Фатих Әмирхан турында истәлекләр / төз.: Ф. Ибраһимова, Р. Әмирхан. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 255 б.

***Заһидуллина Дания Фатих кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әдәбият белеме бүлеге баш гыйльми хезмәткәре*

***Загидуллина Дания Фатиховна,***
*доктор филологических наук, профессор, главный научный сотрудник*
*отдела литературоведения Института языка, литературы*
*и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*zagik63@mail.ru*